СОВЕТ МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Декабристов, д.35 а, с. Печищи,
422592

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы,
422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ                    КАРАР

28.11.2025          с. Русское Макулово          №3-21

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең Рус Макылы торак пункты территориясендә үзара салым кертү һәм аннан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Уставы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районының
Макыл авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2025 елның 10 декабренә Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Рус Макылы авылы җирлеге территориясендә гражданнар арасында үзара салым акчасын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2026 елда Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Рус Макылы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән сез килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

«ӘЙЕ»          «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Рус Макылы авылы, Заречная урамы, 18 нче йорт адресы буенча 14.00 сәгатьтә.

4. Макыл авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районының
Макыл авыл җирлеге башлыгы П.Е. Карпухин